СОВЕТ
МОЛЬКЕЕВСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ КАЙБИЦКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ
МӘЛКИ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

17.02.2026 ел №10

Мәлки ав.

Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Мәлки авыл җирлегенең генераль планын әзерләү кирәклеге булмау турында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 18 статьясындагы 6 пункты нигезендә, Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Мәлки авыл җирлеге территориясендә җирлек территориясен куллануны үзгәртү, Татарстан Республикасын һәм Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районын комплекслы социаль-икътисадый үстерүнең расланган программасы һәм территориаль планлаштыру схемалары күздә тотылмавын, федераль, региональ һәм җирле әһәмияттәге объектларны урнаштыру каралмаганлыгын истә тотып, Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Мәлки авыл җирлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

1. 2026 елның 30 декабренә кадәр Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Мәлки авыл җирлегенең генераль планын әзерләү кирәклеге булмавын танырга.
2. Әлеге карарның гамәлдә булуы 2026 елның 01 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.
3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында, Кайбыч муниципаль районының Мәлки авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында һәм «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://molkeev-kaybici.tatarstan.ru веб-адресы буенча рәсми сайтында бастырып чыгарырга.
4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Совет Рәисе,
Татарстан Республикасы
Кайбыч муниципаль районы
Мәлки авыл җирлеге Башлыгы Ф.П.Поляков